Рәссам белән очрашу // Мәдәни җомга. – 2024. – №1 (12 гыйнвар). – Б. 4.



# Рәссам белән очрашу

«Яшәү сәнгате» мәдәни-агарту үзәгендә рәссам Хәмзә Шәрипов белән иҗади очрашу узды.

Ин әүвәл постмодернизм белән таныштыру булды, чөнки Хәмзә Шәриповның иҗади мирасын тикшерүчеләр аны шушы юнәлешкә кертә. Дәүләт сынлы сәнгать музееның өлкән фәнни хезмәткәре, сәнгать белгече Рәзилә Ильясова кунакларга постмодернизм рәссамнарының үзенчәлекләре турында сөйләде һәм дөнья сынлы сәнгатендә якты эз калдырган исемнәрне атады.

«Постмондернизм – элек традицион классик сәнгать белән берничек тә бәйле булмаган өлкә. Хәзерге сәнгатьтә безне чолгап алган бөтен нәрсәне без постмодернизмга кертә алабыз, аның күп вариацияләре, бәйләнешләре һәм формалары бар», – дип билгеләп үтте Р.Ильясова үзенең чыгышында.

«Йолдыз Нигъмәтуллина, Гүзәл Фәйзрахманова кебек Казан сәнгать белгечләре раславынча, Хәмзә Шәрипов иҗатын постмодернизм контекстында карарга кирәк. Бу хронологик кысалар белән дә, рәссам күзаллаган диалог белән дә, останың халыкны хәйран калдырган образларны тамашачыга тәкъдим итүе белән дә бәйле», – дип билгеләп үтте ул.

Хәмзә Шәрипов 1957 елда Пермь крае Барда районы Аклыш авылында туган. Мухина исемендәге Санкт-Петербург сәнгать-сәнәгать академиясен тәмамлый. 1987 елдан Яр Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итә.

Үзенең чыгышын Хәмзә Шәрипов «Яшәү сәнгате» үзәгенә тәкъдим иткән рәсемнәре белән таныштырудан башлады. Һәркайсының ничек барлыкка килгәне, аларга нинди мәгънә салынганы турында сөйләде. Аның фикере буенча, әсәр тудыруда рәссамның нәрсә әйтергә теләгәне мөһим. Моның өчен үзеңнең дөньяга карашың һәм кыйммәтләр системасы булырга тиеш.

«Шәхес булу, гел үзең өстендә эшләү мөһим. Безгә балачакта нәрсә яхшы һәм нәрсә начар икәнен өйрәтәләр, һәм без гомер буе башка кешеләрнең сүзләре белән уйлыйбыз, бу безнең үзебезнең уйларыбыз дип уйлыйбыз. Кеше үзенә: «Мин чыннан да шулай



уйлыйммы?», дип сорау бирә башлагач кына шәхескә әверелә, – дип сөйләде Х.Шәрипов. – Шәхеснең дөньяга үз карашы бар. Рәсем ясыймы, шигырь яки музыка язамы, ул дөньяга үз әсәре аша нәрсәдер җиткерә. Берәрсе артыннан кабатлап, сәнгать белән шөгыльләнү мөмкин түгел».

Х.Шәрипов булачак рәссамнарга кирәк фикерләре белән уртаклашты: үз юлыңны үтәргә, йөрәгеңне тыңларга һәм үсеш өстендә эшләргә. Кешенең эчендәгесе – рәссамның картиналарында чагылыш таба. «Әгәр эчке дөньяң фәкыйрь икән, иҗат та шундый булачак. Бай, киң булса, сез рәсемнәр аша дөньяга яктылык бирә аласыз. Рәссам бу хакта уйлаганда, ул җәмгыятькә файда китерә, һәм бу аңа кире кайта», – дип билгеләп үтте ул.

**«Яшәү сәнгате» мәдәни-агарту үзәгенең матбугат үзәге.**

Scanned with AnyScanner